**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты составына үзгәрешләр кертү турында

Кайбер затларның башка эшкә күчүе һәм вазыйфалары атамалары үзгәрүе сәбәпле **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 4 июнендәге ПУ-503 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-460 номерлы, 2018 елның 27 гыйнварындагы ПУ-109 номерлы, 2018 елның 17 ноябрендәге ПУ-778 номерлы, 2020 елның 21 июлендәге ПУ-432 номерлы һәм 2020 елның 25 ноябрендәге ПУ-432 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комитет составыннан Н.М. Владимировны, Г.Р. Нәҗиповaны, З.Н. Сафинаны чыгарырга;

б) Комитет составына кертергә:

Вяткина Алиса Львовнаны – «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе генераль директоры вазыйфаларын башкаручыны;

Комитетның секретаре итеп раслап, Сибгатуллина Мәдинә Шәүкәт кызын – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесен;

Яковлев Константин Геннадиевичны – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы советы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы советы Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

в) Комитет әгъзалары вазыйфаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.В. Королевның – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының хокукый мәсьәләләр һәм иҗтимагый экспертиза комиссиясе рәисе» (килешү буенча)»;

М.Н. Максимованың – «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының социаль мәсьәләләр һәм хәйриячелек комиссиясе рәисе, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең социаль эш һәм шәфкать туташы булу өчен югары белем алу факультеты деканы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 21 июнь
№ ПУ-503